**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021елның «16» ноябреннән № 446

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы педагогик хезмәткәрләренә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыру өстәмәләрен билгеләү турында» 2019 елның 16 сентябрендәге 229 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы педагогик хезмәткәрләренә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыру өстәмәләрен билгеләү турында» 2019 елның 16 сентябрендәге 229 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

«Муниципаль белем бирү оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә, гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә куючылар Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы спорт министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган айлык стимуллаштыру өстәмәләрен бирү тәртибе» (алга таба - Тәртип) дигән кушымтада «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан

Республикасы спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипнең 1 пунктында «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында pravo. tatarstan. ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фәсахов